| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

28.06.2022 ел Баулы шәһәре №120

2022 елда Баулы муниципаль
районы сулыкларында кешеләрнең
иминлеген тәэмин итү турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, “Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында” 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы “Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен раслау турында” карары белән Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан сулыкларда кешеләрнең иминлеген һәм гомерен саклауны тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 23 апрелендәге 256 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләренә (алга таба - Кагыйдәләр) таянырга һәм үтәргә

2. Баулы шәһәренең ачык шәһәр бассейнын су коену һәм массакүләм ял итү өчен оештырылган урын итеп билгеләргә һәм аны, Татарстан Республикасы буенча Россия кулланучылар күзәтчелеге идарәсенең (Татарстан) Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге белән килештереп, массакүләм ял итү һәм су коену өчен кулланырга.

3. Баулы шәһәре һәм Баулы муниципаль районы территориясендә Халыкның җиһазландырылмаган (билгеләнмәгән) урыннарда коенуын тыярга

4. Авыл җирлекләре башлыкларына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- авыл җирлекләре территориясендә су коену һәм массакүләм ял итү өчен урыннар билгеләргә, Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә пляжларны төзекләндерергә;

- җиһазландырылмаган (билгеләнмәгән) урыннарда халыкның коенуы тыелуы турында билгеләр куярга.

5. «Баулы-ГорСервис» МКПына 2022 елның 1 июленә кадәр Баулы шәһәренең ачык шәһәр бассейнында Россия Федерациясе Су кодексының 6 нчы маддәсе, 27 нче маддәсе нигезендә һәм Кагыйдәләрдә билгеләнгән таләпләр нигезендә пляж оештырырга тәкъдим итәргә.

6. Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан сулыкларның (буаларны, ачык бассейннарны, пляж зоналарын) куркынычсызлыгын тикшерү комиссиясенең кушымтада бирелгән составын (алга таба - комиссия) расларга.

7. Комиссиягә Баулы муниципаль районының сулыкларын (буаларны, ачык бассейннарны, пляж зоналарын) 2022 елның 1 июленә кадәр карап чыгарга.

8. Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге начальнигына рөхсәт ителгән пляж зоналарында хокук тәртибен саклауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

9. «Татмедиа» ААҖ «Баулы-Информ» филиалына елга һәм сулыклар тирәсендә үз-үзеңне тоту кагыйдәләре, шулай ук җиһазланмаган, куркыныч һәм су коену өчен тыелган урыннар турында халыкка мәгълүмат бирүне оештырырга тәкъдим итәргә.

10. “Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының спорт һәм туризм үсеше бүлеге” МКУ җитәкчесенә йөзү күнекмәләренә, җәйге чорда балалар, үсмерләр һәм яшьләр арасында суда үз-үзеңне тотуның гомуми кагыйдәләренә, экстремаль вәзгыятьтә эш итү буенча күрсәтмә чаралар оештырырга.

11. «Баулы-ГорСервис» МКПын су өстендә зыян күрүчеләргә беренче ярдәм күрсәтү өчен су коену сезоны чорында Баулы шәһәренең ачык шәһәр бассейны территориясендә кизү торуны оештырырга тәкъдим итәргә.

12. Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең (Татарстан) Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарындагы территориаль бүлеге башлыгына Баулы муниципаль районы сулыкларында эпидемиологик хәлне тикшереп торуны тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

13. Халык ялы өчен билгеләнгән урыннарда 2022 елның су коену сезонын 1 июльдән 31 августка кадәр билгеләргә.

14. Базалар һәм ял лагерьлары территориясендә су коену өчен ясалма сулыклар булган оешмалар җитәкчеләренә Кагыйдәләр нигезендә су объектларында гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларын оештырырга тәкъдим итәргә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://www.pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы сайтында (http://www.bavly.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе И.И. Гозәеров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының
2022 елның 28 июнендәге
120 номерлы карары белән
расланган

Баулы муниципаль районы территориясендә урнашкан сулыкларның (буаларны, ачык бассейннарны, пляж зоналарын) куркынычсызлыгын тикшерү комиссиясе составы

Гозәеров И.И. - Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе, комиссия рәисе;

Алексеев Г.В. - «Баулы үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибы (килешү буенча);

Ганиева Д.З. - «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы мәгариф бүлеге» МКУ начальнигы;

Иванов А.Г. - Россия Эчке эшләр министрлыгының Баулы районы буенча бүлеге начальнигы (килешү буенча);

Михайлова А.А. - «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының

| | | |
|---|---|---|
| | | мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы» МКУ җитәкчесе; |
| Сәбитова А.З. | - | Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең (Татарстан) Бөгелмә, Азнакай, Баулы, Ютазы районнарында территориаль бүлеге әйдәүче белгече (килешү буенча); |
| Сафиуллин Р.Р. | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең инраструктура үсеше буенча урынбасары; |
| Хөснуллина И.И. | - | Баулы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча беренче урынбасары. |